КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 12 гыйнвар г.Казань № 3

Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен бәяләү һәм Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше документациясен әзерләү, раслау һәм аңа төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә үзгәрешләр кертү зарурлыгын билгеләү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу карарга теркәлгән Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрү турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына 30 көн эчендә Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрү өчен кирәкле белешмәләр исемлеген, әлеге белешмәләрне бирүче затлар исемлеген һәм аларны бирү тәртибен расларга.

3. «Татарстан Республикасының Пространствоны планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесен Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение итеп билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2024 ел, 12 гыйнвар, 3 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын
гамәлгә ашыруга мониторинг үткәрү турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмәдә Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасын гамәлгә ашыруга мониторинг (алга таба – мониторинг) үткәрү максаты һәм бурычлары куела, мониторинг эшләренең эчтәлеге һәм мониторинг эшләренең нәтиҗәләрен тапшыру тәртибе билгеләнә.

1.2. Мониторинг объекты – Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы, шулай ук башка шәһәр төзелеше документациясе, шул исәптән Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы (алга таба – Министрлык) боерыгы белән исемлеге раслана торган мониторинг үткәрү өчен кирәкле белешмәләр.

1.3. Мониторинг мәгълүмати, методик, аналитик эшләр, шулай ук шәһәр төзелеше документациясен камилләштерү һәм аңа төзәтмә кертү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү эшләрен башкару юлы белән үткәрелә.

## II. Терминнар һәм билгеләмәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр һәм билгеләмәләр кулланыла:

мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение – әлеге Нигезләмәгә таянып, мониторинг үткәрүче «Татарстан Республикасының Пространствоны планлаштыру институты» дәүләт бюджет учреждениесе;

шәһәр төзелеше документациясе – Татарстан Республикасының территориаль планлаштыру схемасы, муниципаль районнарның территориаль планлаштыру схемасы, җирлекләрнең һәм шәһәр округларының генераль планнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирдән файдалану һәм йортлар салу кагыйдәләре, Татарстан Республикасы территориясен планлаштыру документациясе, җир кишәрлекләренең шәһәр төзелеше планнары, төзелешкә рөхсәт, әлеге документацияне әзерләгәндә кулланыла торган документлар;

белешмәләр – Министрлык боерыгы белән исемлеге раслана торган мониторинг объектына карый торган мәгълүмат;

үзара хезмәттәшлектә катнашучылар – Министрлык боерыгы белән исемлеге раслanучы, үзара хезмәттәшлектә катнашучылар һәм мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение арасында төзелгән мониторинг үткәргәндә мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү нигезендә мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение адресына белешмәләр бирүче затлар.

## III. Мониторингның максаты һәм бурычлары

3.1. Мониторингның максаты – Татарстан Республикасының шәһәр төзелешен бәяләү һәм Татарстан Республикасы территориясендә шәһәр төзелеше документациясен әзерләү, раслау һәм аңа төбәк һәм муниципаль дәрәҗәләрдә үзгәрешләр кертү зарурлыгын билгеләү.

3.2. Мониторингның бурычлары:

расланган шәһәр төзелеше документациясенә үзгәрешләр кертү кирәклеген билгеләү;

шәһәр төзелеше документациясен әзерләгәндә һәм раслаганда мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение, үзара хезмәттәшлектә катнашучылар һәм шәһәр төзелеше мөнәсәбәтләренең башка субъектлары арасында үзара хезмәттәшлекне оештыру;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге шартлары үзгәрүгә бәйле рәвештә, шәһәр төзелеше документациясен үз вакытында актуальләштерү;

җирдән файдалану нәтиҗәлелеген арттыру;

территориаль социаль-икътисадый үсешне фаразлау һәм нигезләү төгәллеген арттыру.

## IV. Мониторинг эшләренең эчтәлеге

4.1. Мониторинг эшләренә мәгълүмати, методик, аналитик эшләр, шулай ук шәһәр төзелеше документациясен камилләштерү һәм аңа төзәтмә кертү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү эшләре керә.

4.2. Мәгълүмати эшләр Министрлык боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә белешмәләр алуны үз эченә ала.

4.3. Методик эшләр мониторинг үткәрү буенча методик тәкъдимнамәләр эшләүне үз эченә ала.

4.4. Аналитик эшләр әлеге Нигезләмәнең 4.3 пунктында күрсәтелгән методик тәкъдимнамәләрне куллану юлы белән әлеге Нигезләмәнең 4.2 пунктында күрсәтелгән мәгълүмати эшләр уздыру нәтиҗәсендә алынган белешмәләр нигезендә Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше документациясен гамәлгә ашыруга бәя бирүне үз эченә ала.

4.5. Шәһәр төзелеше документациясен камилләштерү һәм аңа төзәтмә кертү турындагы тәкъдимнәрне әзерләү эшләре шәһәр төзелеше документациясенә үзгәрешләр кертү турында тәкъдимнәр әзерләүне үз эченә ала.

## V. Мониторинг үткәрү тәртибе

5.1. Мониторинг үзара хезмәттәшлектә катнашучылардан алынган белешмәләр нигезендә мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение тарафыннан гамәлгә ашырыла.

5.2. Үзара хезмәттәшлектә катнашучыларның мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждениегә белешмәләр тапшыру һәм аларны актуальләштерү тәртибе, ысуллары, сроклары һәм дәвамлылыгы Министрлыкның боерыгы белән билгеләнә. Мониторинг

үткәрүгә вәкаләтле учреждение һәм үзара хезмәттәшлектә катнашучылар арасында үзара хезмәттәшлек, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнарының, җирле үзидарә органнарының электрон рәвешендәге мәгълүмати хезмәттәшлекне Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат үзәге ресурсларыннан файдалану юлы белән оештыру турында» 2009 елның 12 февралендәге ПУ-69 номерлы Указы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәткәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек итү тәртибе турында» 2012 ел, 7 август, 674 нче карары таләпләрен исәпкә алып, мониторинг үткәргәндә мәгълүмати хезмәттәшлек турында килешү нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3. Дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләр Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары таләпләре нигезендә үзара хезмәттәшлектә катнашучылар тарафыннан тапшырыла.

## VI. Мониторинг эшләре нәтиҗәләрен бирү тәртибе

6.1. Әлеге Нигезләмәнең IV бүлегендә каралган эшләрне башкару нәтиҗәләре буенча мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение үткән чор өчен мониторинг нәтиҗәләре турында еллык доклад (алга таба – еллык доклад) проектын һәм мониторингның оператив планнарын әзерләүне тәэмин итә.

6.2. Еллык доклад мониторинг нәтиҗәләре күрсәтелгән документтан (шул исәптән Татарстан Республикасының шәһәр төзелеше үсешен бәяләү өлешендә), шулай ук Татарстан Республикасының территориаль һәм социаль-икътисадый үсеше нәтиҗәлелеген арттыру буенча тәкъдимнәрдән гыйбарәт.

6.3. Мониторингның оператив планнары һәм еллык доклад проекты Министрлыкка мониторинг үткәрүгә вәкаләтле учреждение тарафыннан Министрлык тарафыннан билгеләгән тәртиптә һәм срокларда тапшырыла.

6.4. Еллык доклад Министрлык тарафыннан, хисап елыннан соң килә торган елның 30 сентябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Рәисенә һәм Татарстан Республикасы Премьер-министрына тапшырыла.

6.5. Еллык доклад рәсми сорау буенча хезмәттәшлектә катнашучыларга бирелә.